ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 23 » июнь 2018 ел № 103

Хезмәт (вазыйфа) урынында үз-үзен тотуга куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында», Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә:**

1. Кушымта итеп бирелгән Хезмәт (вазыйфа) урынында үз-үзен тотуга куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәне расларга.

2. 2016 елның 1 ноябрендәге 190 номерлы карар белән (2018 елның 20 мартындагы 63 номерлы редакциядә) расланган муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урынында үз-үзләрен тотуга, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаларында үз-үзләрен тотуга таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы ярдәмчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы
башлыгы Р.Р. Нотфуллин